ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БОРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

19.12.2018 | с. Татарское Бурнашево | 21

Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге территориясендә
янгынга каршы махсус режим кертү турында

“Янгын куркынычсызлыгы турында” 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм “Янгын куркынычсызлыгы турында” 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 07 декабрендәге 1088 номерлы карары нигезендә Яңа ел бәйрәм чараларының, гражданнарның тормышы һәм сәламәтлеге, физик һәм юридик затлар, дәүләт яисә муниципаль мөлкәт мөлкәтенең янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында

КАРАР БИРӘМ

1. 2018 елның 20 декабреннән 2019 елның 09 гыйнварына кадәр Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим кертергә.
2. Җирлектә яшәүчеләрнең һәм кунакларның фейерверклар үткәрү урыны итеп - Юмат авылына таба автомобиль юлын (Земледелец кибете артында) расларга.
3. Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, Яңа ел һәм раштуа бәйрәмнәре вакытында социаль әһәмияткә ия объектларны саклауны көчәйтү буенча җаваплы зат итеп Бурукин Сергей Валерьевичны билгеләргә.
4. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Борнаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районының
Борнаш авыл җирлеге башлыгы С. В. Бурукин